**ГЛАВА ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2024 елның 20 марты — № 2

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Горшково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 13.10.2023 №1 гражданнар җыены карарына, 13.10.2023 №2 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Горшково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 13.10.2023 №1 гражданнар җыены карарына, 13.10.2023 №2 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 31 мартында 10.00 сәгатьтә Горшково авылы, Болын урамы, 54 йорт адресы буенча урнашкан Горшково авыл клубы бинасында гражданнар җыены уздырырга.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 13.10.2023 №1, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 13.10.2023 №2 гражданнар җыены карарларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә ризамы:

**-** торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуция челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында "бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru., «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Горшково авылы, Күл арты урамы, 35А йорт мәгълүмат стендында кабул ителгәннән соң 10 эш көне дәвамында игълан итәргә.

4. Әлеге карар аның басылып чыгуыннан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Ленино
авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина